**Казан шәһәренең Идел буе районы**
**78 номерлы «Фарватер» лицее**

# БАТЫРЛЫКЛАРЫ ОНЫТЫЛМАСЫН ИДЕ...

Башкаручы: 4 «Б» сыйныф
укучысы Булатова Кәримилә
Җитәкчесе: Игитова Н.А.

Казан шәһәре
2019

*Авыл тулы калды әби-чәби,*
*Хатын-кызлар, үсмер малайлар.*
*Дөнья йөге алар җилкәсендә,*
*Ачтан үксеп елый сабыйлар…*

*Көнне төнгә ялгап, ару белми,*
*Хатын-кызлар эшкә тотынды.*
*Шул чагында сугыш яланында,*
*Бер-бер артлы»туплар»атылды….*
*Гөлсем Нәбиуллина*

Бөек Ватан сугышының тынганына җитмеш биш елдан артык вакыт үтте. Мин үзем дә, әти-әнием дә, әби-бабам да сугыш чорын күрмәдек. Бу кан койгыч сугыш турында үзебезнең карт әби, карт бабаебыздан ишетеп кенә беләбез.

1941 елда безнең илебезгә фашист гаскәрләре басып кергән. Ватанны, илебезне, җиребезне сакларга бөтен халык бердәм булып күтәрелгән. Безнең буынны, якты киләчәгебезне саклап калган кешеләрнең батырлыгы беркайчан да онытылмасын иде! Шул сәбәпле бу теманы бик актуаль дип саныйм – безнең әби-бабаларыбызның әлеге җиңүгә керткән батырлыклары һәрвакыт истә булырга тиеш. Кызганычка каршы, сугышта катнашкан, тылда фидакарь хезмәт куйган ветераннар саны елдан-ел кими. Шуңа күрә исәннәрнең кадерен белеп калырга кирәк. Һәрбер кеше үзенең нәселенең тарихын белергә тиеш. Сугыш афәтенең һәр кеше, һәр гаилә өчен фаҗига булуын күрсәтү, илебез тарихы белән кызыксыну, тыныч тормышның кадерен белергә өйрәтү – безнең мөһим бурычларыбыз.

Әлеге проектта мин үземнең карт әбием тыл ветераны Исмәгыйлова Өммехания Гәрәй кызының тормыш юлын өйрәнү максаты куйдым.

Әлеге максатка ирешү өчен мин гаилә архивы белән таныштым, әбиемнең үзеннән сораштым, шулай ук дәү әти, дәү әнидән дә белештем.

Безнең гаиләдә Җину көнен бик зурлап бәйрәм итәләр. Барлык туганнар җыелып, бакыйлыкка күчкән сугыш ветераны бабабыз Исмәгыйлов Әбрар Йосып улы каберенә чәчәкләр итәбез. Шулай ук ел саен 9 нчы май көнендә Бөек Җиңүгә багышланган бәйрәм парадын карарга барабыз,

«Үлемсез полк» сафларына чыгабыз. Безнең куанычыбыз булган тыл ветераны ак әбиебез Исмәгыйлова Өммехания Гәрәй кызына олы ихтирам күрсәтәбез.

Әбием бик озын һәм авыр тормыш юлы үткән. Ул 1922 елның 10 февралендә хәзерге Питрәч районы Кибәк иле авылында күп балалы гаиләдә дөньяга килә. Идел буендагы 1921 елгы котычкыч ачлык, Гражданнар һәм Беренче Бөтендөнья сугышларныннан соң газаплы еллар була бу.

Әби кечкенәдән эшләп үсә. Әти-әниләре эштә вакытта, кечкенә ир һәм кыз туганнарын карау аның җаваплылыгында була. Колхозлаштыру елларының сынаулары аша да уза, ачлы-туклы яшүсмерләр колхоз кырларында, мал абзарларында, ындыр табагында олылар белән берәттән эшлиләр. Белем алу өчен, берничә чакрым ераклыкта урнашкан зуррак авылларга барып, мәктәптә укыйлар. Нык арган булсалар да, кичке уеннарны да калдырмыйлар.

Әби еш кына үзенең зәңгәр башмакларын искә ала. Ачлы-туклы вакытта, кием-салымга бик зур мохтаҗлык була. Әтисе Теләче базарыннан аңа матур зәңгәр төстәге башмаклар алып кайта. Әле башмакларны әби бик саклап кына кия. Бервакыт аларны күршедәге иптәш кызы ниндидер бәйрәмгә барырга сорап тора. Әмма кире кайтарганда, аяк киеменең төсе уңып беткән була, әби үзенең башмакларын кызганып елаганлыгын искә алып сөйли.

Әле егермесе тулмаган кыз балага сугыш елларында ирләр өчен дә авыр булган хезмәт куярга туры килә. Авылдагы ир-атларны бер-бер артлы сугыш кырларына озаталар. Әбиемнең олы абыйсын да сугышка озаталар. Кызганычка каршы, 1942 елда ук аның, Сталинград өчен сугышларда камалышта калып, хәбәрсез югалуы турында хәбәре килә.

Әби сугышның беренче көннәреннән алып склад мөдире, соңыннан бригадир булып эшли. Ул яшүсмерләр, карт-коры, хатын-кызларның тылдагы авыр тормышын еш искә ала: авыр йөк күтәрүләре, ачлы-туклы таңнан алып төнгә кадәр эшләүләре, фронтка озату өчен икмәк әзерләүләре, үгез җигеп

җир сөрүләре – барысы да аның башыннан узган. Шуңа өстәп гаиләләренә тагын бер күңелсез хәбәр килә: яше тулмаса да, кече энесен дә Кызыл армия сафларына алалар. Аны Суслангер урманнарына өйрәнүләргә озаталар. Әбием әтисе белән энесенә җылы кием һәм ашарга ризык алып барганнарын хәтерли.

Сугыштан соң илне хәрәбәләрдән торгызу да хатын-кыз, балаларның җилкәсенә төшә. Тормыш берничә дистә елдан соң гына җайлаша төшә.

Әбием Ямәширмә авылына бер кешегә кияүгә чыга. Әмма аз гына яшәп кала, тормыш иптәше үлеп китә. Әбине Салкын Чишмә авылына Әбрар бабама димләп кияүгә бирәләр. Бабай бу вакытта 4 баласы белән тол калган була. Әби кечкенә ятимнәрнең әниләрен алмаштыра, аларга җан җылысын кызганмый. Ул барлыгы 8 балага ана була.

Әби пенсия яшенә кадәр Ленино-Кокушкино совхозында хезмәт куя. Лаеклыклы ялга чыккач, олылайган каенанасын, оныкларын тәрбияләшә.

Әби бик диндар кеше. Ул биш вакыт намазын калдырмый. Җиде сыйныф белемле генә булса да, яңалиф, латин, рус графикасындагы китапларны яхшы укый. Бүген дә, күзлек кигән килеш, дини китапларны укырга тырыша.

Әбием холкы белән дә бик яхшы кеше, ул бик сабыр һәм тыныч. Кирәк вакытта, үзенең төпле киңәшен дә бирә, чын халыкчан тәрбия системасына таянып, безне дә үстерешә.

Хәзер минем әбиемә 97 яшь, ул дәү әнием һәм дәү әтием белән Питрәч районы Салкын Чишмә авылында гомер кичерә.

Әбием тагын озак еллар безне шатландырып яшәсен иде. Без аңа гаиләбез белән бик рәхмәтле, аны бик ихтирам итәбез. Безнең киләчәгебезне бәхетле итү өчен бәяләнеп бетергесез өлеше өчен аның алдында баш иябез.

Тик шулай да, күпме еллар узса да, халык хәтерендә Бөек Ватан сугышы иң авыр, иң дәһшәтле сугыш буларак сакланыр, һәм халкыбызның кылган батырлыклары һәрвакыт хөрмәт һәм соклану белән искә алыныр.